Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«26» май 2020 ел № 17

Шәһәр җирлеге мөлкәте белән эш итү
вәкаләтләрен тапшыру һәм муниципаль берәмлекнең
рәсми сайтында шәһәр җирлеге мөлкәте
объектлары реестрларын, шулай ук кече
һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү
өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен
бастырып чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Саба муниципаль районы Советы мөрәҗәгате һәм «sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгыннан файдаланып арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өлеше» индикаторын үтәү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 21.01.2020 елдагы киңәшмәсе Беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты вәкаләтләрен тапшыру тәкъдимен кабул итү турында:

- шәһәр җирлеге милке белән эш итү буенча;

- муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында шәһәр җирлеге мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

- әлеге карарны тормышка ашыру максатында, бюджет закончалыкларына туры китереп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советына «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең 2020 нче елга һәм 2021 – 2022 елгы план чорына бюджеты турында» Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2019 елның 19 декабрендә кабул ителгән 46нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» гы Карары проектын эшләргә һәм карау өчен тәкъдим итергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары Р. М Хәсәнов